**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Загорье бистәсендә гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

**5 декабрь 2021 ел** **№1**

2003 елның 06 октябрендәге 131-03 номерлы «Россия Федерациясендә җирле узидарә оештырунын гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьясы, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Азнакай муниципаль районы Вахитов авыл җирлеге Уставы нигезендә 2021 елның 05 декабрендә түбәндәге сорау буенча узган гражданнар җыеннары нәтиҗәләре буенча гаражданнар жыенының йомгаклау протоколы төзелде:

«Сез, 2022 елда 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм анда катнашучылар, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан тыш, Азнакай муниципаль районы Вахитов авыл җирлеге Загорье торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертү һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга тоту белән ризамы:

- Загорье торак пунктында юлларны кардан чистарту (ягулык-майлау материаллары сатып алу, шартнамә буенча хезмәт күрсәтүләр һәм эшләр өчен түләү);

-Загорье торак пункты Үзәк урамы буенча җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын карап тоту (асфальт-бетон өслекле юлларның чокырларын ямау.

Гражданнар жыены нәтижәләре турында беркетмә нигезендә: Жыенда катнашучылар исемлегенә сайлау хокукына ия 59 гражданнар җыенында катнашучы теркәлгән, халык жыенында катнашып тавыш биргән гражданнар саны 33.

Тавыш бирү нәтижәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары тубәндәгечә бүленде:

«РИЗА» позициясе өчен 33, «КАРШЫ» позициясе өчен 0 гражданнар җыенында катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар итте:

1. Азнакай муниципаль районы Вахитов авыл жирлеге Загорье торак пунктында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыенынын нәтиҗәләре – гамәлдә дөрес дип танырга.

2.Түбәндәге сораулар буенча карарны кабул ителгән дип танырга: «Сез, 2022 елда 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм анда катнашучылар, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан тыш, Азнакай муниципаль районы Вахитов авыл җирлеге Загорье торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500

сум күләмендә үзара салым кертү  һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга тоту белән ризамы:

- Загорье торак пунктында юлларны кардан чистарту (ягулык-майлау материаллары сатып алу, шартнамә буенча хезмәт күрсәтүләр һәм эшләр өчен түләү);

-Загорье  торак пункты  Үзәк урамы буенча җирле әһәмияттәге  автомобиль юлларын карап тоту (асфальт-бетон өслекле юлларның чокырларын ямау.

3. Әлеге карарны, кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә, Вахитов авыл җирлеге мәгълумати стендларында һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында (http://aznakaevo.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы хокукый мәгълуматының  рәсми сайтында» (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Вахитов авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Халык жыенында рәислек итүче,
Азнакай муниципаль районы
Вахитов  авыл җирлеге башлыгы: И.Б. Бохарова